**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.08.2024 № 969

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясен төзү турында» 2021 елның 18 гыйнварындагы 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 гыйнварындагы 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Үз эшчәнлегендә Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгы карарларына һәм күрсәтмәләренә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин